ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2022 г. Заинск № 605

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мобилизацияле әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (2022 елның 23 маендагы 250, 2022 елның 08 июлендәге 336, 03.10.2022 елның 03 октябрендәге 505 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1 кушымтада түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.1.6. пунктында «хәрби хезмәт үтүче һәм махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләнгән гражданнарның балалары»

сүзләрен «өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән, яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнар гаиләләреннән:»

1.2. Түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе 5 бүлегенең 5.2 пункты бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә алынган, яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарның балалары:»

1.3. Түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе 5 бүлегенең 5.2 пункты унберенче абзацында **«- хәрби хезмәт узучы мобилизацияләнгән гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары:»** сүзләрен **«өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә алынган гражданнарның, яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарның балалары:»** сүзләренә алмаштырырга.

3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар рәсми бастырылган көннән законлы көченә керә һәм 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42